«Татарстан Республикасы  Зеленодольск муниципаль районының
7 нче гомуми урта белем мәктәбе» муниципаль бюджет  гомумбелем
учреждениесе

# Күңелем түрендә авылым тарихы

Башкарды: Сабирова Әдилә
10нчы сыйныф укучысы
Укытучы: Бикмөхәммәтова Ләйсән
Гаделҗан кызы,
туган тел һәм әдәбияты укытучысы

Яшел Үзән/2020нче ел

Эчтәлек 2

I. Кереш 3-4

II. Төп өлеш 5-8

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Әрә авылы турында белешмә

2. Яшел Үзән районы Әрә авылының топонимикасы

3. Яшел Үзән районы Әрә авылының билгеле кешеләре

III. Йомгаклау 8-9

IV. Библиография 10

# КЕРЕШ

## Теманың актуальлеге.

Исемнәр – тарих хәбәрчеләре. Авыл атамаларында, кабер ташларында, язуларда, шәҗәрәләрдә (кабер ташларындагы нәсел агачы) бик күп исемнәр бүгенге көнгә исән-сау килеш килеп җиткәннәр. Географик җирлекләрнең күбесенә бик борынгы заманнарда ук исемнәр бирелгән. Халкыбызның борынгы теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре турында сөйләүче байтак мәгълүматлар тупланган аларда. Туган авылларда, туган төбәкләрдә күпме ачылмаган серләр көтеп ята. Һәр тау-чокыр һәм күл-инеш исеме үзе бер ачылмаган дөнья бит. Исемнәрне җыйнарга, өйрәнергә кирәк.

Татар халкы төрле сәбәпләр аркасында шактый ерак араларга сибелеп утырган, халыкның формалашу тарихы катлаулы. Шул катлаулылык халыкның килеп чыгышында, ономастикасында, гореф-гадәтләрендә, йолаларында чагылыш таба.

Мин үземнең бу эзләнү-тикшерү эшемдә Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Әрә исемендәге татар авылының ономастикасын өйрәнүне максат итеп алдым.

Барлык төр географик берәмлекләрне тәфсилләп өйрәнү, халкыбызның борынгыдан кулланып килгән тел җәүһәрләрен берәмтекләп барлау кыйммәтле мәгълүматлар бирә. Исем-атамалар үзләре хезмәт күрсәткән халыкның элекке заманнардан ук кемнәр белән аралашуын, тормышка карашын, рухи кыйбласын, тарихи үсеш юлын, мәдәни дәрәҗәсен, тарихи бәйләнешен ачыкларга ярдәм итә.

Географик атамаларның барысы да онытылып беткәнче, җыеп туплау мәсьәләсен көн кадагы итеп күтәрергә кирәк.

Авыллар тарихы, географик берәмлек атамалары хакындагы мәгълүматларны мин шул авылда яшәүче тарих укытучыларыннан, авыл картларыннан, зыялы кешеләрдән сорашып тупладым. Аларның дөрес

сөйләүләрендә инану өчен район архивында да булырга туры килде. Кыскасы, күп кешеләр белән аралашылды, шуңа күрә минем хезмәтем юкка булмаган дип ышанып каласы килә.

Тел белеменең ономастика дип йөртелә торган бер тармагы бар. Бу фәннең тикшерү өлкәсе ифрат бай һәм кызыклы. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрне һәм кушаматларны, күк җисемнәренең һәм географик урыннарның, шул җөмләдән елга-суларның, мифологик затларның исем-атамаларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыю-туплау, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны тормышка ашыра.

Ономастика фәнендәге табышлар һәм казанышлар тел тарихын өйрәнүдә генә түгел, бәлки халыкның этник тарихын яктыртуда да зур әһәмияткә ия.

Соңгы елларда халкыбызның рухи мирасын барлауга һәм өйрәнүгә игътибар бик нык артты. Рухи мәдәниятебезнең нигезе булган туган телне саклау, үстерү зарури вә гаять тә олуг бер эш итеп карала башлады.

Татар халкы һәм аның теле дигәндә, без, беренче чиратта, телне саклауда иң ныклы тотка булган авылны һәм авыл халкының телен күз алдында тотабыз.

Хезмәтне башкарганда, Г.Ф. Саттаровның “Татар топонимиясе”, Ф.Г. Гарипованың “Исемнәрдә - ил тарихы” дигән китаплардан файдаландым. Хезмәт кереш, төп өлеш, йомгак һәм библиографиядән тора.

## ТӨП ӨЛЕШ

### I. Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Әрә авылы турында белешмә

Әрә авылының күптәнге карталары, аларның бабалары, әбиләре Әрә авылының тарихын болай сөйли торган булганнар. Әрәдән ике чакрым ераклыкта иске Өрәңгәр, рус телендә “Старое Муратово” дигән чуваш авылы бар. Анда беренче килеп утырган кеше Морат бакый исемле кеше булган, шуннан авыл зураеп үсеп киткән. Морат бакый картаеп үлгәч, ул ислам динендә булганга күрә, иске Өрәңгәр авылы зиратына күмелгән. Байтак читкәрәк – көнчыгышка таба алып китеп, аны сөзәк бер тау итәгенә күмгәннәр. Бәлки, аның васыяте дә булгандыр. Иске Өрәңгәр ислам, христиан диннәрендә ике төрле халык булып яшәгәннәр булса кирәк. Ислам динендә булган кешеләр берәм – берәм аерылып китә башлаганнар. Үзләренә кечкенә бер авыл ясаганнар. Ул авыл бер кечкенә елга буена туры килгәнгә, шул елга исемле булып йөргән. Елга Әрә исемле булган. Әрә елгасы моннан 15 чакрым көнбатыштарак Әрә башы дигән зур чуваш авылыннан башланып китә. Шуннан агып килеп, бездән 20 чакрым җир агып китеп рус авылы Бритвино белән татар авылы Молвино арасында Зөя суына кушыла икән. 35 чакрым Әрәнең юлы өстендә күпме авыл бар, шул авыл кешеләре барысы да ул елганы бүгенгә кадәр Әрә диләр. “Иске Өрәңгәрдә” ике төрле кешеләр яшәвен дөресли торган авыллар бар. Бездән 6 чакрым җирдә “Исламово” дигән авыл бар, анда яртысы руслар, яртысы татарлар булган. Революциядән соң 1928 елны күп язулар белән артыннан йөреп татарлар аерылганнар.

### II. Яшел Үзән районы Әрә авылының топонимикасы

Әрә авылы бик кечкенә булган. Тирә якка бик билгеле булмаган, урманнар яшереп торган. Әрә суы буеннан Казанга үтә торган олы юл булган. Аннан төрле юлчылар, артистлар, лашманчылар узганнар. Ял итүне авыл тирәсенә ясаганнар. Кечкенә Әрәнең кеп-кечкенә карындык тәрәзәләрен тишеп, баш киемнәрен салып, өй эченә узалар икән дә тоз, шырпы бир, сөт,

йомырка бир, кәгазь кебек әйберләрне сорыйлар икән. Кайберләре икмәкләрен, хайваннарын сорамыйча алып киткәннәр. Бу кечкенә Әрәне шулай рәнҗеткәннәр. Кечкенә Әрәне кайбер елларда язгы кар-су ташкыннары да аптыраштa калдырган. Халыкка зур зыян китергән. Әрә авылы кешеләре үзара уйлашканнар, киңәшләшкәннәр дә, безгә биредә яшәүнең бер дә тынычлыгы булмас ахыры, бервакытта да без бәла-казалардан  котыла алмабыз, безгә әнә теге тугайга күчү кирәк, шуннан башка безгә яхшы урын булмас диешкәннәр. Халык бик күндәм булган, бу киңәшне дөрес табып бер авыздан риза булганнар. Күп тә үтмичә, тугайга – тау башына тәвәкәлләп күчкәннәр. Алар үлгән кешеләрне Морат бакый кабере янына күмә башлап, зиратлары шуннан башланып киткән. Шушы вакыттан башлап Әрә - Тугай дип аталу паралель кулланыла. Тугай тау башына күчкәч тә яңа зират шул булып калган, зурайган. Авылның Тугай – тау күчүен әнә шул зиратның ераклыгы да дөресләп тора.

Башта авылның Түбән оч, Су буе урамнары гына булган, аннары әкренләп кырга таба үсә, җәелә башлаган. 1880 елларда кыркапкасы II мәхәллә мәчете янында гына булган. Тагын төньяк басуларга гына чыга торган капка булган, аны кушкапка дигәннәр. Ул капкалар хәзер юк, ә урыннары шул исемнәр белән атап йөрткәннәр.

Әрә суы буенда 5 су тегермәне булган. Әрә авылы ике чакрым көньяк – көнбатышкарак Можар авылының Евграф исемле рус кешесе бер тегермән тоткан. 1890 елда беткән. Буасының карт өянкеләре озак еллар торган. Биредә Евграф тегермәне дип, тегермән урыны дип озак еллар атап йөрткәннәр. Евграф тегермәне өянкеләреннән узып бераз баргач, юл сөзәк тауны ерып кереп торган җирдә, Әрә авылының, Әрә басуында Суык кизләү булган. Аны Акъегет авылы Шәфигулла улы Заһидулла дигән бай кеше ясаткан. Чишмәсе үтә суык һәм тибеш аккан, шунда ук бер бакча да ясаткан. Анда зифа буйлы таллар, тирәкләр үскән. Кызу урак өсләрендә кешеләр шунда савытлар, тырыслар күтәреп су алырга килгәннәр.

Әрә авылының төньяк басуында 2 чакрым җирдә бик борынгы, куе, кыяклы күл булган. Аны Шәмкүл дигәннәр. Буе 100 метрдан артыграк, аркылыга 40 метр итеп 1911нче елда хөкүмәт аны чистарткан, тирәнлеге 2,5 метр булган. Кармыш юлы дигән борынгы зур юл Шәмкүл белән Каенсаз арасыннан узган. Каенсаз дигән сазлык, Шәмкүл икесе дә куе урман кап-караңгы булып торган. Юлчылар аннан шәм яндырып узганнар. Шуңа күрә исемен дә Шәмкүл дип атаганнар.

Каенсаз урынында сазлык булган. Юлдан язып адашу куркынычы зур булган. Юл Шәмкүл белән Каенсаз уртасыннан үткән. Хәзер бу урында, сазлыгы да юк. Каенсаз дигән сазлыкта суы җәй буе буылып торса да, тирән булмаган. 1928 – 29 – 30 нчы елларда сазлык бөтенләйгә беткән. Каеннары бу заманаларга калмаса да, өч төп карама калган.

Чуваш авылы Масыл белән чиктәш җирдәрәк Мурач – кизләве дигән кизләү булган. Бу кизләү турында хәзер белүчеләр юк. 1860 нчы елларда Шәмкүлгә тоташа төшкән уңга табарак куе, матур урман булган. Аңа Хачирмә дигәннәр. Чокырларында чишмәләр тулып агып яткан. Балан, миләш, чикләвек, чия күп булган. Урманын кисеп бетергәннәр. Хәзер бер нәрсәсе дә юк. Җире шулай дип атала. Хачирмә чуваш сүзе булса кирәк.

Җәрмәк чокыры – шушы чокырдан язгы душкынлы кызыл сулар агып төшкән, җәрмәк төште дигәннәр, ягъни ермак төште.

Кирмәт тавы – тауның исеме гарәп сүзеннән алынган булса кирәк (серле, изге урын). Бу тауны изге урын диеп акчалар салганнар. Кирәмәт тавы астында зур ташлары булган каберлек булган. Ташларын соңгы вакытта алганнар, яхшы кешеләр күмелгән диеп сөйлиләр.

## III. Яшел Үзән районы Әрә авылының билгеле кешеләре.

Һәр төбәк гамәлләре матур кешеләре белән билгеле. Үзләренең күркәм эшләре, тоткан кыйблалары белән киләчәк буыннарга тирән эз калдырган шәхесләр яши. Матур табигатьле, җыр-моңга, шигърияткә, хуш исле болыннарга, урманнарга, челтерәп аккан чишмәләргә бай булган Әрә авылы,

бик күп сәләтле ул-кызлар үстереп, бүген алар белән горурланып яши. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская – беренче татар хатын-кыз актрисасы (әтисе Әрәдән). Милли театрыбызның оешуында һәм үсешендә беренче татар хатын-кыз артисты Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның өлеше аеруча зур. Ул – мөселман хатын-кызлары арасыннан кыю рәвештә театр сәхнәсенә чыккан батыр йөрәкле кызларның берсе. Арыслан Батыршин - композитор, Мөхәммәтхан Фазлуллин – профессор, Әминә апа Фазлуллина – ветеран укытучы (бүген Айдар авылында яши), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илгизәр Фазлуллин - шагыйрь, “Күгеш чишмәләре” китабы авторы, Якуб Зәнкиев – язучы (әнисе Әрәдән), Сәрия Сабурская (әтисе Әрәдән), Лут Низамиев – химия фәннәре кандидаты. Шушы яктан, шушы туфрактан алар.

# ЙОМГАКЛАУ

Йомгаклап әйткәндә, һәр халыкның үз теле, үз тарихы бар, ул үз тамырларын аңларга, белергә тели. Шушы җәһәттән татар халкының җирле географик терминнарын тикшерү дә халыкның телен, тарихын һәм тамырларын белү-өйрәнүдә үзеннән шактый зур һәм мөһим өлеш кертә.

Һәркемне туган җиренә, аның урман-кырларына, тау-үзәннәренә, елга-суларына, юл-сукмакларына, болын-көтүлекләренә, сала-калаларына нәкъ менә аларның тарихларын, атамаларын кайчан, кемнәр тарафыннан бирелүен һәм нәрсә аңлатуын, лексик мәгънәләрен белү, белергә теләү беректерә, туган җирнең, туган якның кадерен, газизлеген һәм якынлыгын шулар арттыра, милли тамырларны шулар ныгыта, беркайчан һәм берничек тә өзелмәс итә.

Бик борынгы, ерак заманнардан башлап, ыруг-кабиләләр, халыклар үзләренең туган телләрендә дөньядагы бөтен нәрсәгә, җанлысына, җансызына, аларның сыйфатына, халкына, эш-гамәленә карап, һәрберсенә муафыйк исем-атама биргәннәр. Һәркайсының исеменә җисеме муафыйк булып, туры килеп, килешеп тора.

БИБЛИОГРАФИЯ


1. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. – Казан: КДУ нәшрияты, 1990. - 276 б.
2. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. – Казан: КДУ нәшрияты, 1998.- 438 б.
3. Район архивыннан материаллар.
4. Авылымның өлкән кешеләре (Халикова Сания апа, Сәлимуллин Корбан абый, Гатауллина Сәкинә апа, Гарифуллина Әминә апа).